# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О представителях интересов государства в органах управления и контроля хозяйственных обществ

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
8 июня 2023 года

### Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон регулирует отношения в сфере назначения, выдвижения для избрания, согласования назначения и выдвижения для избрания представителей интересов Республики Татарстан в органах управления и контроля хозяйственных обществ (далее – представитель интересов государства), а также вопросы согласования указанными лицами позиции при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственными обществами.

### Статья 2. **Правовые основы деятельности представителей интересов государства**

Представители интересов государства осуществляют свою деятельность в соответствии с федеральным законодательством, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, определяющими порядок назначения, выдвижения для избрания, согласования назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства и согласования указанными лицами позиции при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственными обществами.

### Статья 3. **Общие требования к представителям интересов государства, порядку назначения, выдвижения для избрания, согласования назначения и выдвижения для избрания в органы управления и контроля хозяйственных обществ**

1. Представителями интересов государства могут быть лица, замещающие государственные должности Республики Татарстан, должности государственной

гражданской службы Республики Татарстан, а также иные лица в соответствии со статьей 9 настоящего Закона.

2. Назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства осуществляются в органы управления и контроля следующих хозяйственных обществ:

1) в отношении которых принято решение об использовании специального права («золотой акции»);

2) акции (доли в уставных капиталах) которых находятся в собственности Республики Татарстан;

3) акции (доли в уставных капиталах) которых принадлежат хозяйственным обществам, более 50 процентов акций (долей в уставных капиталах) которых находится в собственности Республики Татарстан.

3. Назначение, согласование назначения представителей интересов государства осуществляются в органы управления и контроля следующих хозяйственных обществ:

1) в отношении которых принято решение об использовании специального права («золотой акции»);

2) 100 процентов акций (долей в уставных капиталах) которых находится в собственности Республики Татарстан.

4. В случаях, не указанных в части 3 настоящей статьи, осуществляются выдвижение для избрания, согласование выдвижения для избрания представителей интересов государства.

5. Лица, замещающие государственные должности Республики Татарстан, должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, осуществляют представление интересов государства в органах управления и контроля хозяйственных обществ на безвозмездной основе.

Статья 4. **Органы, осуществляющие назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства**

Назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства осуществляются:

1) Главой (Раисом) Республики Татарстан;

2) Государственным Советом Республики Татарстан;

3) Кабинетом Министров Республики Татарстан;

4) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений.

Статья 5. **Назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства Главой (Раисом) Республики Татарстан**

Распоряжением Главы (Раиса) Республики Татарстан осуществляются:

1) назначение, выдвижение для избрания в органы управления и контроля хозяйственных обществ, акции которых находятся в собственности Республики Татарстан, имеющих особо важное значение для экономики Республики Татарстан, представителей интересов государства, замещающих должности Главы (Раиса) Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, заместителей Премьер-министра Республики Татарстан, Руководителя Администрации Главы (Раиса) Республики Татарстан, руководителей республиканских органов исполнительной власти, должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Администрации Главы (Раиса) Республики Татарстан, Аппарате Кабинета Министров Республики Татарстан, республиканских органах исполнительной власти;

2) назначение, согласование назначения в органы управления и контроля хозяйственных обществ, указанных в пункте 1 части 2 статьи 3 настоящего Закона, а также назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания в органы управления хозяйственных обществ, указанных в пункте 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона, представителей интересов государства, замещающих должности Главы (Раиса) Республики Татарстан, Премьер-министра Республики Татарстан, заместителей Премьер-министра Республики Татарстан, Руководителя Администрации Главы (Раиса) Республики Татарстан, руководителей республиканских органов исполнительной власти, должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Администрации Главы (Раиса) Республики Татарстан, Аппарате Кабинета Министров Республики Татарстан, республиканских органах исполнительной власти;

3) согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства в органы управления и контроля хозяйственных обществ, указанных в пункте 3 части 2 статьи 3 настоящего Закона.

### Статья 6. **Назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства Государственным Советом Республики Татарстан**

1. Постановлением Государственного Совета Республики Татарстан осуществляются:

1) назначение, выдвижение для избрания депутатов Государственного Совета Республики Татарстан в органы управления хозяйственных обществ, указанных в пунктах 1 и 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона;

2) согласование осуществления депутатами Государственного Совета Республики Татарстан полномочий представителей интересов государства в органах управления хозяйственных обществ в случаях, предусмотренных пунктом 3 статьи 5 и пунктом 1 части 1 статьи 7 настоящего Закона.

2. Депутаты Государственного Совета Республики Татарстан осуществляют полномочия представителей интересов государства в органах управления хозяйственных обществ до дня начала работы Государственного Совета Республики Татарстан нового созыва.

Статья 7. **Назначение, выдвижение для избрания, согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства Кабинетом Министров Республики Татарстан**

1. Распоряжением Кабинета Министров Республики Татарстан осуществляются:

1) назначение, выдвижение для избрания в органы управления и контроля хозяйственных обществ, указанных в пунктах 1 и 2части 2 статьи 3 настоящего Закона, включенных в перечень, указанный в пункте 1 части 2настоящей статьи, представителей интересов государства на основании согласования назначения и выдвижения для избрания, предусмотренного пунктом 2 статьи 5 и пунктом 2 части 1 статьи 6 настоящего Закона;

2) назначение, выдвижение для избрания в органы управления и контроля хозяйственных обществ, указанных в пунктах 1 и 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона, включенных в перечень, указанный в пункте 2 части 2настоящей статьи, представителей интересов государства, замещающих должности руководителей республиканских органов исполнительной власти, должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Аппарате Кабинета Министров Республики Татарстан, республиканских органах исполнительной власти;

3) согласование назначения и выдвижения для избрания в органы управления хозяйственных обществ, указанных в пункте 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона, назначение, выдвижение для избрания в органы управления которых осуществляются органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, представителей интересов государства, замещающих должности руководителей республиканских органов исполнительной власти.

2. Кабинетом Министров Республики Татарстан утверждаются:

1) перечень хозяйственных обществ, представители интересов государства в органы управления и контроля которых назначаются, выдвигаются для избрания Кабинетом Министров Республики Татарстан после согласования с Главой (Раисом) Республики Татарстан;

2) перечень хозяйственных обществ, представители интересов государства в органы управления и контроля которых назначаются, выдвигаются для избрания Кабинетом Министров Республики Татарстан.

Статья 8. **Назначение, выдвижение для избрания представителей интересов государства органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений**

Распоряжением органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области имущественных отношений, осуществляются:

1) назначение, выдвижение для избрания в органы управления хозяйственных обществ, указанных в пункте 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона, представителей интересов государства, замещающих должности руководителей республиканских

органов исполнительной власти, – на основании согласования назначения и выдвижения для избрания, предусмотренного пунктом 3 части 1 статьи 7 настоящего Закона;

2) назначение, выдвижение для избрания в органы управления и контроля хозяйственных обществ, указанных в пунктах 1 и 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона, представителей интересов государства, замещающих должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Аппарате Кабинета Министров Республики Татарстан, республиканских органах исполнительной власти, – на основании письменных предложений соответственно Кабинета Министров Республики Татарстан, республиканских органов исполнительной власти;

3) согласование назначения и выдвижения для избрания представителей интересов государства в органы управления и контроля хозяйственных обществ, указанных в пункте 2 части 2 статьи 3 настоящего Закона, управление акциями (долями в уставных капиталах) которых осуществляется юридическими или физическими лицами на основании договоров и соглашений, предусматривающих передачу в доверительное или иное управление, хозяйственное ведение.

Статья 9. **Представление интересов государства на основании договора на представление интересов Республики Татарстан в органах управления и контроля хозяйственных обществ**

1. Помимо лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, представителями интересов государства могут быть назначены иные лица, отвечающие квалификационным требованиям, определяемым Кабинетом Министров Республики Татарстан.

2. Иные лица, указанные в части 1 настоящей статьи, осуществляют представление интересов государства в соответствии с договором на представление интересов Республики Татарстан в органах управления и контроля хозяйственных обществ, заключаемым в соответствии с гражданским законодательством с органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений.

Статья 10. **Согласование позиции при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственным обществом**

1. Представители интересов государства обязаны в письменной форме согласовывать позицию при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственным обществом с органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, по следующим вопросам:

1) внесение изменений в учредительные документы хозяйственного общества;

2) ликвидация и реорганизация хозяйственного общества;

3) изменение величины уставного капитала хозяйственного общества;

4) назначение, избрание конкретных лиц в органы управления и контроля хозяйственного общества, образование единоличного исполнительного органа

хозяйственного общества, утверждение условий трудового договора с единоличным исполнительным органом хозяйственного общества, в том числе о достижении показателей (индикаторов) социально-экономического положения хозяйственного общества, определение размера и порядка выплаты единоличному исполнительному органу хозяйственного общества вознаграждения (премий или иных выплат), досрочное прекращение полномочий единоличного исполнительного органа хозяйственного общества;

5) совершение хозяйственным обществом сделки, в совершении которой имеется заинтересованность;

6) совершение хозяйственным обществом крупной сделки, связанной с приобретением или отчуждением хозяйственным обществом имущества, стоимость которого составляет 25 и более процентов балансовой стоимости активов хозяйственного общества, а также по передаче указанного имущества в доверительное управление, аренду, залог (ипотеку);

7) участие хозяйственного общества в создании иных коммерческих организаций (в том числе учреждение дочерних хозяйственных обществ), финансово-промышленных групп, ассоциаций и объединений;

8) совершение хозяйственным обществом сделки или нескольких взаимосвязанных сделок, связанных с приобретением, отчуждением или возможностью отчуждения хозяйственным обществом прямо либо косвенно имущества, стоимость которого составляет 10 и более процентов балансовой стоимости активов хозяйственного общества;

9) совершение хозяйственным обществом сделок с недвижимым имуществом.

2. При наличии в одном органе управления хозяйственного общества нескольких представителей интересов государства предварительно определяется единая позиция представителей интересов государства при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственным обществом.

3. Порядок согласования представителем интересов государства позиции при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственным обществом, порядок определения единой позиции представителей интересов государства при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственным обществом устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

4. Представители интересов государства, нарушившие установленный порядок согласования позиции при голосовании по проектам решений по вопросам управления хозяйственным обществом, а также голосовавшие не в соответствии с результатами согласования, несут ответственность в соответствии с законодательством.

Статья 11. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Республики Татарстан**

Признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 19 октября 2000года № 383 «О порядке участия представителей государства в органах управления и контроля

хозяйственных обществ и товариществ» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 11 (9);

2) Закон Республики Татарстан от 12 декабря 2005 года № 122-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О порядке участия представителей государства в органах управления и контроля хозяйственных обществ и товариществ» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 12 (I часть);

3) статью 2 Закона Республики Татарстан от 7 октября 2015 года № 70-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О приватизации государственного имущества Республики Татарстан» и отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 10 (I часть);

4) статью 10 Закона Республики Татарстан от 6 апреля 2023 года № 24-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2023, № 27 (часть I).

Статья 12. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
20 июня 2023 года
№ 55-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 8 июнендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне (алга таба – дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкил) билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне, шулай ук күрсәтелгән затлар тарафыннан хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә үз позициясен килештерү мәсьәләләрен җайга сала.

## 2 статья. **Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр үз эшчәнлекләрен федераль законнар, әлеге Закон һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү тәртибен һәм күрсәтелгән затлар тарафыннан хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә үз позициясен килештерү тәртибен билгели торган башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыралар.

## 3 статья. **Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләргә, хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү тәртибенә карата гомуми таләпләр**

1. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр булып Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук әлеге Законның 9 статьясы нигезендә башка затлар тора ала.

2. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү түбәндәге хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына гамәлгә ашырыла:

1) аларга карата махсус хокукны («алтын акция») куллану турындагы карар кабул ителгән;

2) акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган;

3) акцияләренә (устав капиталларындагы өлешләренә) хуҗалык җәмгыятьләре ия булган, аларның акцияләренең (устав капиталларындагы өлешләренең) 50 процепттан артыгы Татарстан Республикасы милкендә була.

3. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, билгеләп куюны килештерү түбәндәге хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына гамәлгә ашырыла:

1) аларга карата махсус хокукны («алтын акция») куллану турындагы карар кабул ителгән;

2) акцияләренең (устав капиталларындагы өлешләренең) 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелмәгән очракларда дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне сайлау өчен күрсәтү, сайлау өчен күрсәтүне килештерү гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне түләүсез нигездә башкаралар.

4 статья. **Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп куюны, сайлау өчен күрсәтүне, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерүне гамәлгә ашыручы органнар**

Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Рәисе;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы.

**5 статья. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү**

Татарстан Республикасы Рәисе күрсәтмәсе белән түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган, Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча әһәмияткә ия булган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү;

2) Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына билгеләп кую, билгеләп куюны килештерү, шулай ук әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарына билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;

3) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү.

**6 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү;

2) әлеге Законның 5 статьясындагы 3 пунктында һәм 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган очракларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны килештерү.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр вәкаләтләрен яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшли башлаган көнгә кадәр гамәлгә ашыралар.

7 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән, әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына әлеге Законның 5 статьясындагы 2 пунктында һәм 6 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү нигезендә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү;

2) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән, әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү;

3) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән, аларның идарә итү органнарына билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарына республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан түбәндәгеләр раслана:

1) хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге, аларның идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр Татарстан Республикасы Рәисе белән килештергәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела, сайлау өчен күрсәтелә;

2) хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге, аларның идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела, сайлау өчен күрсәтелә.

8 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы күрсәтмәсе белән түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү органнарына әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү нигезендә республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү;

2) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, республика башкарма хакимият органнарының язмача тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү;

3) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән, аларның акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре) белән идарә итү ышанычлы идарә итүгә яисә башка төрдәге идарә итүгә, хуҗалык итүгә тапшыру карала торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә юридик яисә физик затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү.

9 статья. **Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итү шартнамәсе нигезендә дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итү**

1. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр булып, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлардан тыш, Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче башка затлар да билгеләнеп куела ала.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән башка затлар дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы белән граждан законнары нигезендә төзелә торган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итү шартнамәсенә таянып гамәлгә ашыралар.

10 статья. **Хуҗалык җәмгыяте белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә позицияне килештерү**

1. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр, хуҗалык җәмгыяте белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы белән түбәндәге мәсьәләләр буенча үз позициясен язма рәвештә килештерергә тиеш:

1) хуҗалык җәмгыятенең гамәлгә кую документларына үзгәрешләр кертү;

2) хуҗалык җәмгыятен бетерү һәм үзгәртеп кору;

3) хуҗалык җәмгыятенең устав капиталы күләмен үзгәртү;

4) хуҗалык җәмгыятенең идарә итү һәм тикшереп тору органнарына конкрет затларны билгеләп кую, сайлау, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органын төзү, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органы белән хезмәт шартнамәсе шартларын раслау, шул исәптән хуҗалык җәмгыятенең социаль-икътисадый хәле күрсәткечләренә (индикаторларына) ирешү турында, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органына бүләкләү (премияләр яисә башка түләүләр) күләмен һәм аны түләү тәртибен билгеләү, хуҗалык җәмгыятенең бердәнбер башкарма органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

5) хуҗалык җәмгыяте тарафыннан аны гамәлгә ашыруда кызыксыну булган алыш-бирешне башкару;

6) хакы хуҗалык җәмгыяте активларының баланс хакыннан 25 һәм аннан да күбрәк процент тәшкил иткән мөлкәтне хуҗалык җәмгыяте тарафыннан сатып алуга яисә читләштерүгә, шулай ук әлеге мөлкәтне ышанычлы идарәгә, арендага, залогка (ипотекага) тапшыруга бәйле эре алыш-бирешне хуҗалык җәмгыяте тарафыннан башкару;

7) хуҗалык җәмгыяте тарафыннан башка коммерциячел оешмалар төзүдә катнашу (шул исәптән кече хуҗалык җәмгыятьләрен гамәлгә кую), финанс-сәнәгый төркемнәр, ассоциацияләр һәм берләшмәләр төзүдә катнашу;

8) хакы хуҗалык җәмгыяте активларының баланс хакыннан 10 һәм аннан да күбрәк процент тәшкил иткән мөлкәтне хуҗалык җәмгыяте тарафыннан турыдан-туры йә читләтеп сатып алуга, читләштерүгә яисә читләштерү мөмкинлегенә бәйле алыш-бирешне яисә үзара бәйле булган берничә алыш-бирешне хуҗалык җәмгыяте тарафыннан башкару;

9) хуҗалык җәмгыяте тарафыннан күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләр башкару.

2. Хуҗалык җәмгыятенең бер идарә итү органында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче берничә вәкил булганда, хуҗалык җәмгыяте белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә, дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрнең бердәм позициясе алдан билгеләнә.

3. Дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкил тарафыннан хуҗалык җәмгыяте белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә үз позициясен килештерү тәртибе, дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрнең хуҗалык җәмгыяте белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә бердәм позициясен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Хуҗалык җәмгыяте белән идарә итү мәсьәләләре буенча карарлар проектларына тавыш биргәндә үз позициясен килештерүнең билгеләнгән тәртибен бозган, шулай ук тавыш бирүе килештерү нәтиҗәләренә туры килмәгән дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр законнар нигезендә җаваплы булалар.

11 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 11 (9);

2) «Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 12 декабрендәге 122-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 7 октябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 27 (I өлеш).

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 20 июнь
№ 55-ТРЗ